ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 24 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» 2009 елның 17 июнендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 5; 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 8 – 9; 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 50 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацта «Түбәндәгеләрнең» сүзен «1. Түбәндәгеләрнең» сүзләренә алмаштырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:
«2. Әлеге Законда билгеләнгән салым ставкалары, әгәр башкасы Россия Федерациясе Салым кодексының $346^{20}$ статьясындагы $1^{1}$ һәм $2^{1}$ пунктларында билгеләнмәгән булса, салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр тарафыннан кулланырга тиеш.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң бер ай узгач, ләкин салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә түләнә торган

салым буенча чираттагы салым чорының 1 нче числосыннан да иртәрәк түгел, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 28 сентябрь
№ 60-ТРЗ